Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылында
гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре №2

2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге Куакбаш авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлеге Куакбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләреннән тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

2.1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Куакбаш авылында (Совет урамы, Ленин урамы, М. Җәлил урамы, Х. Такташ урамы, К. Маркс урамы, Маяковский урамы, Тукай урамы, Сәйдәшев урамы, Г. Исхакый урамы, Яшьләр урамы) юлларны кардан чистарту

2.2.) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- Куакбаш авылында янгын сүндерү машинасы өчен җылы боксны җылыту

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, Куакбаш авылы, Карл Маркс урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан җирле үзидарә бинасында, Сходнево-Чертанлы авылы Ирек урамы, 5а буенча урнашкан авыл клубы, Чүте авылында Тынычлык урамы 8А буенча урнашкан авыл клубы бинасында урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова